СОВЕТ МАЛОКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.З.Закирова, д.47, с. Малые Кирмени,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422172

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ КИРМӘНАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
З.Закиров ур., 47 нче йорт, Кече Кирмән авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422172

тел.(факс): (85563) 2-96-17; e-mail: MKir.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР
№ 1-47

РЕШЕНИ Е
«18» сентябрь 2019 ел.

## Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Кече Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Советы К А Р А Р К А Б У Л И Т Т Е:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Кече Кирмән торак пунктында Аръяк урамындагы, Норма торак пунктында Үзәк урамындагы, Югары Яке торак пунктында Үзәк урамындагы, Норма урман хуҗалыгы торак пунктында Урман урамындагы юлларны ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);

- Кече Кирмән, Норма, Югары Яке, Су-Елга, Норма урман хуҗалыгы торак пунктларындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Мубаракшинга йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Кече Кирмән авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе Х.Х.Мубаракшин